3 нче а сыйныфының татар төркемендә әдәби укудан ачык дәрес планы.

Тема: К. Насыйри "Ашаганда үзеңне тота белү кагыйдәләре" хикәясе.

Дәрес төре :яңа материал аңлату дәресе(кереш дәрес).

Дәреснең бурычлары:

Предмет нәтиҗәләре: "Ашаганда үзеңне тота белү кагыйдәләре" хикәясе белән таныштыру,эчтәлеген аңлау,сәнгатьле уку күнекмәләрен ныгыту.

Метапредмет нәтиҗәләре:укытучы җитәкчелегендә дәреснең проблемасын(тема) һәм максатларын формалаштыру,үз эшчәнлегеңне контрольгә алу,үзконтроль;эшләнгән эшнең сыйфатын билгеләү күнекмәләрен үстерү.

Шәхси нәтиҗәләр:укучы шәхесенең әхлакый-рухи сыйфатларын камилләштерү,өстәл янында үзеңне тиешенчә тота белү сыйфатлары тәрбияләү;ашханәдә,өйдә дә бу кагыйдәләрне даими рәвештә куллана белергә өйрәтү.

Укытучы һәм укучы өчен ресурслар:

Дәреслек (Уку китабы:рус телендә башлангыч гомуми белем бирү мәктәбенең 3 нче сыйныфы өчен дәреслек (татар балалары өчен) Р.Х.Ягъфәрова. Казан:Татарстан китап нәшрияты,2013);презентация,карточкалар,өстәлләрдә кирәкле материаллар,музыка.

Дәрес барышы

I.Яңа белемнәр үзләштерүгә мотивация булдыру.

Психологик уңай комфорт урнаштыру (Укучылар өч төркемгә бүлеп утыртыла) Хәерле иртә, балалар. Кәефләрегез ничек? Кояшлы иртә кебек.

- Бик яхшы. Кояшлы көнне без бер-беребезгә карап елмаеп, тагын да балкытып җибәрик, бу күтәренке күңел дәрес ахырына кадәр дәвам итсен.

II Белемнәрне актуальләштерү.

а)өй эшен тикшереп үтү. **(Б.Рәхмәт "Аш ваыты" шигыре).<u>Сингл Раунд Робин структурасы.</u>**

<u>-Укучылар</u>!Без шигырь белән танышканда аны ничә өлешкә бүлгән идек?(3).Хәзер һәр төркем шигырьнең үз өлешен сәнгатьле итеп , бер-берегезгә укырга тиеш, үзбәядә укуны истә тотарсыз.Беренче өлешне 1 нче төркем укый.

Икенче өлешне 2 нче төркем, ә 3 нче өлешне 3 нче төркем укый.

-Рәхмәт,укучылар ,булдырдыгыз.

-Дежурный тәлинкә,кашыкларны таратты,балалар ашханәдә үзләрен бик тәртипле тоталар **.**

б)<u>-Укучылар</u>!Экранга карагыз әле!Сез яраткан мультфильм геройлары.Алар сезгә ошыймы? Алар ничек ашыйлар? Өстәл янында үзләрен дөрес тоталармы?Карлсон кул белән ашый.Кашык белән ашамый.Бик пычрак ашый.Песи китап укып ашый,алай шарга ярамый.Ә бу песи күп ашый,күп ашарга да ярамый.

-Әйе,зур кисәк алырга ярамый, ашаганда китап укырга ярамый, кул белән ашарга ярамый...

2.Дәреснең темасын ачыклау.Максат һәм бурычлар кую.

-Укучылар, димәк без бүген нинди темага сөйләшәчәкбез?

<u>Ашаганда үзеңне тота белү кагыйдәләре турында.</u>

III.Яңа теманы "ачу"(эзлеклелекне билгеләү,укчыларның проблеманы хәл итүдә катнашуы)

-Укучылар К.Насыйри да өстәл артында үзеңне ничек тоту кагыйдәләрен сезгә җиткерергә теләгән.Әйдәгез сүзлек өстендә эш эшләп китик, сүз һәм сүзтезмәләрне текстан табып, тәрҗемә итик, алар эчтәлекне аңлауда ярдәм итәрләр.

Үзеңне тота белү кагыйдәләре-*правила этикета за столом;*

Бәрәкәтлерәк-качественное,на долго;

Сеңешлерәк булу-хорошо перевариться;

кайнар килеш-*в горячем виде;*

вак-вак чәйнәп-*мелко жевать;*

уңга-сулга-*направо и налево;*

түкмичә-*не проливая;*

тамызмыйча-*не капая;*

өреп-*надув;*

зиһен-*ум;*

хәтер-*память.*

-Ә хәзер тыңлыйбызмы? (Дәреслектәге текстны уку,70 нче бит).

Укучылар! сәнгатьле укуны төркемнәрдә дәвам итик әле.Сүзне һәр төркемнең 1 нче һәм 3 нче номерлы укучыларга бирәбез.

<u>Укытучы:</u>

-Укучылар!Менә бу рәсемнәргә туры килгән җөмләләрне текстан табып укыйк әле. (рәсемнәр күрсәтелә).

1. Кулны кайчан юарга кирәк? 1.Ризык ашарга утырганда, кулыңны ю.Ашаганнан соң да , кулыңны ю.

2. Ризыкны ничек чәйнәргә кирәк? 2.Вак-вак чәйнәп аша, ашың сеңешлерәк булсын.

3. Өстәл янында үзеңне ничек тотарга кирәк? 3.Ашаган вакытта ,уңга-сулга карама,алдыңа гына карап утыр.Кешенең кисәгенә һәм кашыгына күз салма.

<u>Физминут</u>

Менә минем уң кулым,
Менә минем сул кулым.
Менә –идән,менә-түшәм.
Ә хәзер мин йөгерәм
Һәм йөзәм.

IV.Яңа белемне ныгыту һәм системага салу.

Укытучы.

2.ТИК- ТЭК- ТОУ структурасы белән төркемнәрдә эшләү.

Кәгазьдә язылган сүзләр белән киңәш итү җөмләләре төзегез.

Ашама	***алдыңа, өстәлгә***	**Капма**	***ашама***	**Тамызма**	***аз***
Түкмә	***уңга-сулга***	**Эчмә**	***кеше кашыгына күз***	**Ватма**	***алдыңа карап***
Карама	***терсәгеңне өстәлгә***	**Салма**	***каты өреп***	**Аша**	***алдыңа, өстәлгә***
Куйма	***кайнар килеш***	**Шапырдатып**	***ризыкны зур***	**Утыр**	***савыт-сабаны***

3нче бирем Раунд Тэйбл структурасы.

-Сезнең өстәлләрегездә дүрткә бөкләнгән ак кәгазь.һәрберегез текстан берәр кагыйдәне язып,иптәшегезгә бирә барырга тиеш.Дүрт төрле кагыйдә язылгач, һәр төркемнең 4 нче номерлы укучысы укып чыгачак.

4 нче бирем

-Укучылар !Без укыган текст эчтәлеге буенча нинди мәкальләр һәм әйтемнәр әйтә аласыз?

-Ашыгыз тәмле булсын!

-Ашау-эшне калдырмый.

-Аш –ашка,урыны –башка.

Менә миндә өстәп китим әле,сез дәфтәрләрегезгә язып алырсыз.

-Ашаган сыныгыңны калдырма-иптәшең ташлар.

-Ашаган вакытта телеңне тешләсәң, кунак килә.

Сорау табышмаклар:

-Нәрсә өстәл янында бик кирәк?(авыз).

-Нинди савыттан эчеп булмый?(буш).

- Булдырдыгыз, кул чабыйк әле!

Үзбәя

-Укучылар!Һәр төркемгә дә смайликларны бирергә булдым.Мин сезнең үзегезгә куйган үзбәяләрегезне истә тотып,билгеләр куярмын.

V Йомгаклау һәм рефлекция

-Укучылар! **Рефлексия.**

1.- Дәреснең темасы нәрсә иде?

-Әйдәгез, мультфильм геройларына ярдәм итик,бу кагыйдәләрне кабатлыйк,исләрендә калдырсыннар.

- Ашаганда үзеңне тота белү кагыйдәләре.

2.Әйдәгез һәрберегез җөмләләр белән әйтеп барыгыз.

-Ризык ашарга утырганда,кулыңны ю. Ашаганнан соң да ,кулыңны ю.

-Ризыкны уң кулың белә аша.

-Ризыкны ваклап чәйнәргә кирәк.

-Ашаган вакытта,уңга-сулга карама,алдыңа гына карап утыр.

-Алдыңа түкмичә,тамызмыйча аша.

-Эт ялаган шикелле,шапырдатып ашама.

-Күп ашау- начар эш.

-Аз ашау-файдалы.

- Мәктәптә дә,өйдә дә бу хакта онытмагыз! Сеңелләрегезгә,энеләрегезгә дә әйтегез.

VI.Өйгә эш бирү.1)Кемгә “4” ле билгесе кирәк, ул укучылар 70-71 нче биттәге сорауларга җаваплар әзерләп килергә тиеш;

2)Кемнәр “5” легә тырыша ,алар әти-әниләреннән үзегезне тагын нинди матур гадәтләргә өйрәтүләре турында сорашып, сөйләргә өйрәнеп килергә тиешләр.